РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ВЯЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ВЯЗОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**03.07.2019** № **30**

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Вязовка авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 9 гыйнварында кабул иткән “Документларның күчермәләрен һәм алардан өземтәләрнең дөреслегенә шәһадәтлек итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 9нчы карарына төзәтмәләр кертү турында**

Законнарга туры китерү максатында

КАРАР БИРӘМ:

1. Бөгелмә муниципаль районы Вязовка авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 9 гыйнварында кабул иткән “Документларның күчермәләрен һәм алардан өземтәләрнең дөреслегенә шәһадәтлек итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 9нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5нче бүлекне яңа басмада бәян итәргә:

«5. **Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, ә тагын шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтү функцияләрен башкаручы оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү**

5.1. Шикаять муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яки күпфункцияле үзәкне оештыручы булып торучы тиешле дәүләт хакимиятенә (алга таба – күпфункцияле үзәкне оештыручы), ә тагын шулай ук 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1нче өлешендә каралган оешмаларга язма рәвештә кәгазьдә, электрон формада бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата язылган шикаятьләр турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә

(гамәл кылмавына) карата шикаятьләр күпфункцияле үзәкне оештыручыга яки Россия Федерациясе субъектының хокукый-норматив акҗты буенча билгеләнгән вәкилгә бирелә. 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1нче өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешма җитәкчеләренә бирелә.

Гариза язучы шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтүне сораган запросының 210нчы Федераль законның 15.1нче маддәсендә күрсәтелгән теркәү срогы бозылган очракта;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы бозылган очракта. Бу очракта гариза язучының муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятен судка кадәр (судтан тыш) тикшерү шикаять язылган күпфункцияле үзәккә 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсе, 1.3нче өлешендә билгеләнгән муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә һәм шул тәртиптә йөкләнгән очракта гына мөмкин була.

3) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе хокукый-норматив актларында, Россия Федерациясе субъектларының хокукый-норматив актларында, муниципаль хокукый-норматив актларда каралмаган документлар я мәгълүмат сорау, яисә гамәл кылуны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе хокукый-норматив актларында, Россия Федерациясе субъектларының хокукый-норматив актларында, муниципаль хокукый-норматив актларда каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту федераль законнар һәм Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының аларга туры китереп кабул ителгән башка хокукый-норматив актларында, муниципаль хокукый-норматив актларда каралмаган булса. Бу очракта гариза язучының муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятен судка кадәр (судтан тыш) тикшерү шикаять язылган күпфункцияле үзәккә 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсе, 1.3нче өлешендә билгеләнгән муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә һәм шул тәртиптә йөкләнгән очракта гына мөмкин була.

6) муниципаль хезмәт күрсәткән очракта, мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Бөгелмә муниципаль районы хокукый-норматив актларында каралмаган түләү таләп иткән очракта;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешмалар яки аларның хезмәткәрләре тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында бирелгән документларда җибәрелгән хата яки ялгышны төзәтүдән

баш тарту яки аларны төзәтү срогын бозу. Бу очракта гариза язучының муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятен судка кадәр (судтан тыш) тикшерү шикаять язылган күпфункцияле үзәккә 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсе, 1.3нче өлешендә билгеләнгән муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә һәм шул тәртиптә йөкләнгән очракта гына мөмкин була.

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәтләр күрсәтүне туктату, әгәр дә әгәр дә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту федераль законнар һәм Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының аларга туры китереп кабул ителгән башка хокукый-норматив актларында, муниципаль хокукый-норматив актларда каралмаган булса. Бу очракта гариза язучының муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятен судка кадәр (судтан тыш) тикшерү шикаять язылган күпфункцияле үзәккә 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсе, 1.3нче өлешендә билгеләнгән муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә һәм шул тәртиптә йөкләнгән очракта гына мөмкин була.

10) муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк була торган документларны кабул иткән вакытта беренче тапкыр баш таркан чакта юклыгы, яисә дөрес булмаган өлеше төгәл күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү, 210нчы Федераль законның 7нче маддәсенең 4нче пунктында каралгаен очраклардан тыш. Бу очракта гариза язучының муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятен судка кадәр (судтан тыш) тикшерү шикаять язылган күпфункцияле үзәккә 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсе, 1.3нче өлешендә билгеләнгән муниципаль хезмәтләр күрсәтү тулы күләмдә һәм шул тәртиптә йөкләнгән очракта гына мөмкин була.

5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган хезмәткәренең, җитәкчесенең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, "Интернет" телекоммуникацион-мәгълүмат челтәрен, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтын (http://www.bugulma.tatar.ru), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең бердәм порталын (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелә ала, ә тагын шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында тапшырыла ала.

Күпфункцияле үзәкнең, купфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, "Интернет" телекоммуникацион-мәгълүмат челтәре, купфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы, яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын файдаланып җибәрелә ала, ә

тагын шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында тапшырыла ала.

210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешмалар һәм аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр почта аша, "Интернет" телекоммуникацион-мәгълүмат челтәре, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы, яисә Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең региональ порталын файдаланып җибәрелә ала, ә тагын шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхси кабул итү вакытында тапшырыла ала.

5.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкне оештыручы, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешмалар, яисә югарырак органга (әгәр ул булса) кергән шикаятьләр аны теркәгәннән соң 15 көн эчендә каралырга, ә инде муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкне оештыручы, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешмалар документларны кабул итүдән, җибәрелгән хата яки ялгышларны төзәтүдән баш тарткан, андыйларны төзәтү срогын бозган очракларда – теркәгәннән соң 5 көн эчендә каралырга тиеш.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның атамасы, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, яки муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма, аның җитәкчесе һәм (яки) гамәлләренә шикаять белдерелгән хезмәткәре;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, отчествосы (бкулган очракта), гариза бирүче юридик затның урнашкан урыны, ә тагын шулай ук телефон номеры, электрон почта адресы (булса), җавап җибәреләсе почта адресы;

3) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, яки муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, күпфункцияле үзәктә эшләүче, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма, аның хезмәткәрләре турында мәгълүматлар;

4) муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи заты, яки муниципаль хезмәткәр, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, күпфункцияле үзәктә эшләүче, 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма, аның хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) ризасызлык белдерү өчен шикаять белдерүченең нигезләмәләре. Гариза бирүче аларны раслый торган документлар (әгәр булса) яки аларның күчермәләрен бирә ала.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә язылганнарның шартларын раслый торган документларның күчермәләре кушып бирелә ала. Бу очракта шикаятьтә тапшырыла торган ул документларның исемлеге дә күрсәтелә.

5.6. Шикаять аны бирүче муниципаль хезмәт алучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьләрне карау нәтиҗәсе буенча түбәндәге карарларның берәрсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карар кире кагылырга, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документтагы җибәрелгән хата яки ялгыш төзәтелергә, гариза бирүчегә Россия Федерациясе хокукый-норматив актларында, Россия Федерациясе субъектларының хокукый-норматив актларында, муниципаль хокукый-норматив актларында каралмаган очракта тотылган акчасы кире кайтарып бирелергә мөмкин;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгәннең икенче көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язма формада һәм, аның ихтыяры буенча электрон формада, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында мотивацияле җавап юллана.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында ачыкланган кимчелекләрне кичекмәстән бетерү өстендә Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк, яисә 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган оешма тарафыннан ниләр эшләнгәнлеге турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә, алга таба муниципаль хезмәттән файдалану өчен ниләр эшләргә кирәклеге күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта әлеге карарга килү өчен нигез булган сәбәпләр ачык күрсәтелә, әлеге карар өстеннән шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаятьне тикшерү барышында, яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыклана икән, шикаятьләрне тикшерү вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратурага җибәрә».

2. Калган өлешләрдә карар текстын үзгәрешсез калдырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе В.Н.Соколов